БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?



# ХАЛЫК ИҖАТЫН ҮСТЕРЕРГӘ

Очып-очып биергә, тыпыр-тыпыр итеп «Әпипә» көенә басарга, авыл җирендә үскән татар балаларын бәләкәй чактан ук өйрәтәләр. Ләкин олыларга үрнәк бирүчеләр юк. Бу яктан караганда өлкә буенча 18-20 майда Пономаревка районында үткәрелгән семинар катнашучыларга бик тә җайлы булды. Казан театрыннан чакырылган өлкән балетмейстер В.Я.Хамитов клуб эшчәннәре өчен мастер-класс алып барды. Аның җиңел очып, аягы белән идәнгә тимәгән сыман итеп биюен, матур басуын сокланып карадылар һәм артыннан кабатларга да тырыштылар. Җиде район авылларыннан килгән клуб артислары, җиде кат тир бәреп чыкканчыга кадәр эшләделәр, татар биюләрен биергә өйрәнделәр.

Биюдән тыш клуб хезмәткәрләре үзләренең эшләрендәге тәҗрибәләре белән дә уртаклаштылар.Аның һәркайсы авыл сәхнәсендә үзенчә иҗади, эчтәлекле эш алып бара.

Әммә шулай да аларның һәркайсына ничек итеп башкаларның клуб эшен оештыруы, ничек концертлар үткәрүләре һәм нинди репертуар сайлаулары бик кызыклы. Бу уңайдан Рәсәйнең Атказанган мәдәният хезмәткәре З.Г.Валишинаның чыгышы уңышлы булды.Ул эчтәлекле итеп Әсәкәй районындагы «Чишмә» ансамбленең иҗаты турында сөйләде. Бу төркем бик уңышлы эш алып бара. Шуңа күрә дә халык ансамбле исеменә лаек. Науруз сәхнәсендә «Чишмә» коллективы матур чыгыш ясады.Алар үзләренең артистларча чыгышлары, балкып торган милли костюмнары белән тамашачыларның күңеленә хуш килделәр.

Танылган татар төркемнәре башка авылларда да бар. Мәсәлән, Наурузда «Сандугач» ансамбеле. Аның җитәкчесе Л.Ибатуллина үзенең белемнәрен Оренбург шәһәрендә укуы белән яңартып, үстереп тора. Үзенең тәҗрибәсе белән ул да семинарда уртаклашты. Л.Ибатуллина җитәкчелеге белән районнардан килгән кунаклар «Яна йөрәгем «дигән җыр өйрәнделәр.

Ә инде семинарның өченче көнендә сәхнә хезмәткәрләре нәтиҗәләр ясадылар. «Түгәрәк өстәл « утырышында алар халык фольклоры, татар иҗаты турында сүз алып бардылар. Озак кына итеп үзләренең уйлары белән уртаклаштылар. Алда торган мәсьәләләрне дә искә алдылар. Татар культурасын тагын да күтәреп җибәрергә, халык иҗатын үстерергә дигән бурычлар куйдылар. Ә аның өчен инде һәрбер татар авылында клуб утлары сүнмәскә ,балкып торырга, сәхнә буш тормаска тиеш. Матур татар халык җырлары, биюләре бу мәсьәләне эшкә ашырырга мөмкинчелек бирәчәк.

**И.СУЛЕЙМАНОВА,**
**Пономаревка районы.**

**На снимке:** Асекеевская «Чишма»; практические занятия.



# ГОМЕРЕН МӘКТӘПКӘ БАГЫШЛАГАН

**Дөньяда бар шундый кешеләр — гомер буе үзләренең бурычларын намуслы башкарып, иҗтимагый эшләрдә дә җан атып, халкы өчен яшәүчеләр. Алар үзләре турында авылдашлары, халык күңелендә якты хәтирәләр калдыралар.**

Безнең Науруз авылында шундый кешеләрнең берсе, Бөек Ватан сугышы ветераны, укытучы Валишин Тәлгат абый иде.

2010 ел — укытучылар елы дип, игълан ителде. Шуңа күрә мин үзебезне укыткан укытучыларыбызны искә алып, якташларыбыз белән таныштырып үтәргә булдым.

Укытучы...Бу сүздә никадәр мәгънә, көч −куәт. Укытучы сине беренче мәртәбә каләм тотарга һәм Ана, Ватан сүзләре язарга өйрәтә. Укытучы белгечле, катлаулы һәм шул ук вакытта мавыктыргыч та.Тәлгат абый үзенең бөтен гомерен укытучылык хезмәтенә, мәктәпкә, балаларга багышлый. Аның әтисе Фики абый, әнисе Мәргия апа да авылыбызның беренче укытучылары. 1917 елларда авылыбызның дүрт еллык мәктәбендә балаларга белем биргәннәр. Әтисе белән әнисе һөнәрен улы дәвам итә.

1937 елда Тәлгат абый Науруз авылының җиде еллык мәктәбен тәмамлап, Богырыслан шәһәренең татар-башкорт педагогик училищесына укырга керә. 1940 елда башлангыч мәктәп укытучысы дигән таныклык алып, август аенда юллама белән Науруз авылы мәктәбенә эшкә кайта. Тик ул бер ел гына эшләп калырга өлгерә. Бөек Ватан сугышы башлана. Унтугыз яше дә тулмаган егет сугышка китә.

Тәлгат абый сугышның башыннан азагына кадәр Сталинград, Юго-Западный фронтларында хезмәт итә. Аның сугыш юллары Сталинградны азат итүдә, Донбасс, Украина, Румыния, Болгария, Венгрия, Югославия илләре аша үтә.

Канлы сугыш еллары озак һәм озын була. Тәлгат абый яралар алып, госпитальләрдә ятып, күкрәге тулы орден медальләр белән исән-сау туган авылына 1945 елның ноябрь аенда кайта һәм шул ук елны яңадан мәктәптә эшли башлый. Аның тырышлыгын, үз эшен сөеп эшләвен, балаларны яратуын район хуҗалары күрәләр һәм 1949 елда завуч итеп билгелиләр. 1947-1950 елларда Богырысланда педагогик институтында читтән торып укып, тарих факультетын тәмамлый. Ә инде 1957 елда ул Башкорт дәүләт педагогик институтын читтән торып тәмамлап, диплом ала.

1948 елда Тәлгат абый тормыш юлын Гөлсем апа белән бәйли. Гөлсем апа да математика укытучысы . Ул да 30 елдан артык Науруз урта мәктәбендә үзенең гомерен балаларга багышлый. Алар биш бала тәрбияләп үстерәләр, балаларына югары белем биреп олы тормыш юлына чыгаралар. Ата -аналарының укытучы хезмәтенә булган мәхәббәте балаларына да күчә. Бүгенге көндә алар укытучы династиясен дәвам итәләр. Беренче уллары Фән онтолог-философ, Казан университетында студентларга лекцияләр укый. Авылга кайткан чагында китапханәгә кермичә калмый, үзенең газеталарда чыккан мәкаләләрен алып кайтып тора.

Наиль уллары шул ук КГТУ да математика укыта. Ул физика-математика фәннәре кандидаты, доцент.

Кызлары Зенфира Казан шәһәрендә химия-технология университетының фәнни хезмәткәре булып эшли. Химия-технология фәннәре кандидаты. Әлфия кызлары 1981 елда Казан педагогик институтын уңышлы тәмамлап туган ягына кайта. Ул менә инде 25 елдан артык Науруз урта мәктәбендә 1 категорияле математика укытучысы. Кызганычка каршы, Тәлгат абыйның гомере кыска булды. Сугыш яралары аның исәнлеген нык какшатты һәм ул авыру сәбәпле 1977 елда лаеклы ялга чыга, ә инде 1978 елда бу якты дөньядан китә. Ләкин ул мәңгегә үзе укыткан укучылары, авылдашлары күңелендә. Ул укытучы гына түгел, лектор да иде. Һәрвакыт мәктәптә, клубта лекцияләр белән чыгыш ясап, авылдашларын дөнья яңалыклары белән таныштырып торды. Мәктәптә местком председателе, партия оешмасының секретарь вазыйфасын үтәде. Тәлгат Фики улы тырышлыгы, эшчәнлеге дәүләт тарафыннан югары бәяләнгән, күп санлы Почет грамоталары һәм «Мәгариф отличнигы» исеме бирелә.

Гөлсем апа әлегесе көндә исән-сау, кызы Әлфия, кияве Марс тәрбиясендә яши. Казаннан балалары, оныклары кайтып хәлен белеп торалар. Тормыш дәвам итә.

**1966 уку елы чыгарылышы укучысы Д.Т.ИШМУРАТОВА-ГАББАСОВА, китапханә хезмәткәре.**

# Замечательная поездка

**В начале апреля, группа учащихся 7-8 классов Старокутлумбетьевской школы Матвеевского района побывала в Казани, на познавательно — развлекательной передаче «Тамчы-шоу» телеканала ТНВ.**

Команда «Туган тел», в составе которой были Гиниятуллина Альбина, Гайнулина Анжела, Исхакова Луиза, Гиматдинов Артур и Фаткуллин Артур, одержала победу над командой соперников из Кировской области.

Еще дома, ребята вместе с руководителем Сайфуллиной Расилей Лутфулловной сочиняли стихи на родном языке для представления команды, рисовали эмблемы, готовили рассказ о родном селе, о своих интересах.

По рассказам участников, передача была посвящена географии. В ходе игры проверялось знание морей, океанов, рек и озер, границ, крайних точек нашей Родины и так далее. Но, кроме этого, необходимо было показать отличное знание родного языка, татарского устного народного творчества, национальных музыкальных инструментов и много другого. Ребята волновались, но в победе были уверены.

Три дня в Казани были насыщенными и интересными: дети были на экскурсии по современной Казани, побывали в Кремле, посетили спектакли в татарском театре имени Галиаскара Камала. Встретились с известными артистами и писателем Т.Миннуллиным. Для ребят это был настоящий праздник.

Эту поездку удалось организовать благодаря помощи нашего земляка — руководителя Оренбургского землячества Всемирного татарского конгресса Шарипова Талгата Раисовича. Он полностью взял на себя материальные расходы, помог с транспортом, организовал экскурсии и посещение театра детьми. Это была замечательная поездка, и она навсегда сохранится в сердцах ребят.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевский район.**